**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О присуждении Государственной премии Республики Татарстан имени В.Е. Алемасова в 2018 году**

Рассмотрев предложения Комитета по присуждению Государственной премии Республики Татарстан имени В.Е. Алемасова, **постановляю**:

1. Присудить Государственную премию Республики Татарстан имени В.Е. Алемасова:

1) Касимову Василю Амировичу, кандидату технических наук, доценту кафедры «Инженерная кибернетика» Казанского государственного энергетического университета – за значительный личный вклад в разработку и внедрение на территории регионов России автоматизированных комплексов локационного мониторинга состояния проводов линий электропередачи в режиме реального времени для обнаружения гололеда и повреждений на них с целью обеспечения бесперебойного электроснабжения, предупреждения аварий и минимизации ущерба;

2) Кашапову Рамилю Наилевичу, кандидату технических наук, доценту кафедры биомедицинской инженерии и управления инновациями, заведующему научно-исследовательской лабораторией прототипирования Инженерного института Казанского (Приволжского) федерального университета – за значительный личный вклад в разработку и внедрение в промышленный комплекс Республики Татарстан эффективных методов аддитивного производства сложнопрофильных изделий и конструкций;

3) Фасхутдинову Айрату Ибрагимовичу, кандидату технических наук, начальнику отдела анализа и координации инструментального обеспечения метрологической экспертизы Технологического центра публичного акционерного общества «КАМАЗ» – за значительный личный вклад в разработку и внедрение научно обоснованной методики автоматизированного проектирования прогрессивного режущего инструмента и оснастки для инновационных процессов формообразования деталей автомобилей.

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

Казань, Кремль
20 июня 2018 года
№ УП-451

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**2018 елда Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен тапшыру турында**

Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты тәкъдимнәрен карап тикшергәннән соң **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен түбәндәгеләргә тапшырырга:

1) техник фәннәр кандидаты, Казан дәүләт энергетика университетының «Инженерлык кибернетикасы» кафедрасы доценты Касыймов Васил Әмир улына – Россия төбәкләре территориясендә электр энергиясе белән өзлексез тәэмин итү, аварияләрне булдырмау һәм мөмкин булган зыянны киметү максатларында, алардагы боз кату һәм зыян күргән урыннарны ачыклау өчен электр тапшыру линияләре чыбыклары торышын реаль вакыт режимында локацияле мониторинглауның автоматлаштырылган комплексларын эшләүдәге һәм куллануга кертүдәге зур шәхси өлеше өчен;

2) техник фәннәр кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты Инженерлык институтының биомедицина инженериясе һәм инновацияләр белән идарә итү кафедрасы доценты, прототиплаштыру фәнни-тикшеренү лабораториясе мөдире Кашапов Рамил Наил улына – катлаулы профильле эшләнмәләрне һәм конструкцияләрне аддитив җитештерүнең нәтиҗәле ысулларын эшләүдәге һәм Татарстан Республикасының сәнәгать комплексында куллануга кертүдәге зур шәхси өлеше өчен;

3) техник фәннәр кандидаты, «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте Технология үзәгенең метрологик экспертизаны инструментлар белән тәэмин итүгә анализ һәм аны координацияләү бүлеге башлыгы Фәсхетдинов Айрат Ибраһим улына – алдынгы кискеч инструментларны һәм автомобиль детальләре формалары ясауның инновацияле процесслары өчен җайланмаларны автоматлаштырылган проектлауның фәнни нигезләнгән методикасын эшләүдәге һәм куллануга кертүдәге зур шәхси өлеше өчен.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 20 июнь
№ ПУ-451